КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 17 март г.Казань № 271

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү турында» 2013 ел, 13 июнь, 404 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү турында» 2013 ел, 13 июнь, 404 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 декабрь, 970 нче; 2017 ел, 28 август, 603 нче; 2018 ел, 4 сентябрь, 751 нче; 2020 ел, 12 март, 183 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының хезмәт ресурслары балансы фаразын эшләү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктта:

10.3 пунктчада «Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фонды бүлегенә» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды бүлегенә» сүзләренә алмаштырырга;

10.4 пунктчада «Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Социаль иминият фонды төбәк бүлегенә» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды бүлегенә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин